| | | |
|---|---|---|
| **РАСПОРЯЖЕНИЕ**<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>**БОЕРЫГЫ** |
| 30.12.2023 | | № 411 |

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Мәгариф һәм фән советы карамагындагы фәнни-технологик үсеш буенча эш төркеме турында» боерыгына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Мәгариф һәм фән советы карамагындагы фәнни-технологик үсеш буенча эш төркеме турында» 2022 елның 9 декабрендәге 389 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 17 августындагы 279 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Мәгариф һәм фән советы карамагындагы фәнни-технологик үсеш буенча эш төркеме турындагы нигезләмәдә:

4.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Эш төркеменең эш планы эш төркеменә йөкләнгән бурычларны хәл итү белән бәйле аерым мәсьәләләр буенча төзелгән эш төркеме төркемчәләре тәкъдимнәрен исәпкә алып төзелә.»;

4.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9. Эш төркеме утырышы, әгәр анда әгъзаларының кимендә дүрттән өч өлеше катнашса, эш йөртергә хокуклы дип санала.»;

4.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.12. Эш төркеме эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе башкара.»;

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Мәгариф һәм фән советы карамагындагы фәнни-технологик үсеш буенча эш төркеме (алга таба – эш төркеме) составында:

эш төркеме составыннан Р.И. Һидиятуллинны, Д.Р. Шакировны чыгарырга;

эш төркеме составына түбәндәгеләрне кертергә:

Пелевин Олег Владимировичны – Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасарын;

Яковлев Альберт Валерьевичны – Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасарын;

эш төркеме әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Р.И. Камаловның – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе президиумы аппараты җитәкчесе, эш төркеме секретаре (килешү буенча)»;

Р.М. Карповның – «Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрының беренче урынбасары»;

А.И. Поминовның – «Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары»;

М.Р. Сафиуллинның – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең икътисадый һәм стратегик үсеш мәсьәләләре буенча проректоры (килешү буенча)».

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**